**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

Апас районы Каратун тимер юл станциясе поселогының Мәктәп урамындагы 34-А номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Апас районы Кече Күккүз авылының Пушкин урамындагы 28 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Чүпрәле районы Шланга авылының Фрунзе урамындагы 11 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кайбыч районы Ульянково авылының Елга аръягы урамындагы 2 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Вахитов урамындагы 3 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Профсоюз урамындагы 16 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Кама Тамагы районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының Бакый Урманче урамындагы 5 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Тәтеш районы Башчы авылының Гафури урамындагы 11 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә өч ай дәвамында барлык кош-корт асраучыларга башка хуҗалыкларга яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2018 елның 21 июлендәге ПУ-518 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 16 август
№ ПУ-569